ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ УРАЗБАХТИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРАЗБАХТЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ул.Советская, д.1а, с. Уразбахтино,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422155

Совет ур., 1 нче а йорт, Уразбахты авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422155

тел.(факс): (85563) 2-86-36; e-mail: UrBah.Mam@tatar.ru, www: mamadysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№23 22.11.2018 ел

## 2018 елның «18» ноябреннән референдум карарын гамәлгә ашыру максатларында чаралар планын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Уразбахты авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясенең 2018 елның 19 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Уразбахты авыл җирлеге территориясендә җирле референдум нәтиҗәләре турында» 923 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлеге Башкарма комитеты карар кабул итте:

1. 2018 елның «18» ноябреннән референдум карарын гамәлгә ашыру максатларында чаралар планын расларга.
2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында mamadysh.tatarstan.ru, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән игълан итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Уразбахты авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Г.Шәйхетдинов

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлеге Башкарма комитетының
2018 елның 22 ноябрендәге карарына 1 нче кушымта

**2018 елның «18» ноябреннән референдум карарын гамәлгә ашыру максатларында чаралар планы**

| № п/п | чаралар | Үткәрелә вакыты | җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1. | Үзара салым акчаларын түләү өчен авыл җирлеге гражданнары исемлеген әзерләү | 3 декабрьгә кадәр | Авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 2. | Гражданнарга үзара салым акчаларын түләү тәртибе турында хәбәрнамә җибәрү | 10 декабрьгә кадәр | Авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 3. | Үзара салым акчаларын җыю | 2019 елның 28 февраленә кадәр | Авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 4. | Гражданнарның үзара салым акчасын исәпләп чыгаруның дөреслеген, аларның тулысынча һәм вакытында түләнүен тикшереп тору | даими | Авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 5. | Бирелгән мәгълүматлар буенча үзара салым буенча недоимка торышын анализлау үткәрү | даими рәвештә | Авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 6. | 2018 елның 18 ноябре Җирле референдум карары белән билгеләнгән чараларга чыгымнар сметасын раслау | эш тәртибендә, 2019 елның 15 апреленә кадәр | Авыл җирлеге башкарма комитеты Мамадыш муниципаль районының финанс-бюджет палатасы |
| 7. | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы карары белән расланган Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан | агымдагы финанс елының I кварталы тәмамланганнан соң 15 календарь көн эчендә | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә 1 нче кушымта нигезендә башка бюджетара трансфертлар бирү өчен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына гариза бирү | | |
| 8. | Акчаның максатчан кулланылышын контрольдә тоту | Ел дәвамында | «ТР Мамадыш муниципаль районы Контроль-хисап палатасы» МКУ |
| 9. | Җирле референдум карары белән билгеләнгән чараларның үтәлеше турында авыл җирлеге башлыгы отчеты | елга бер тапкыр | Авыл җирлеге башлыгы |
| 10. | Авыл җирлеге башлыгының Җирле референдум карары белән аны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм (яки) Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән билгеләнгән чараларның үтәлеше турында отчетын халыкка җиткерү | биш көн дәвамында | Авыл җирлеге башлыгы |